РӨСТӘМ БАКИРОВ

# ҺИЧ ТЫНМАСЫН ДАНЛЫ ЧОР ҖЫРЫ




Шигырьләр, җырлар

HM
MIRAS

«Эшеңне гел матур итеп башкар –
кешеләр сөенерлек булсын!»

*Әтием Сәйфулла Бакиров әманәте*



РӨСТӘМ БАКИРОВ

# ҺИЧ ТЫНМАСЫН ДАНЛЫ ЧОР ҖЫРЫ

Шигырьләр, җырлар

КАЗАН
«Халкыбыз мирасы»
2024

УДК 371:78+821.512.145-1-93
ББК 74.100.5:85.31+84(2Рос=Тат) я7
Б19

**Бакиров, Рөстәм Сәйфуллович**
Б19 Һич тынмасын данлы чор җыры: шигырьләр, җырлар [төз. А.И.Һадиева]. – Казан: «Халкыбыз мирасы», 2024. – 40 б.

Ошбу җыентыкта күренекле табиб, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасының атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре, җәмәгать эшлеклесе Рөстәм Бакировның төрле елларда иҗат иткән шигырьләре, җырлары тупланган. Аның иҗаты туган якка, туган туфракка чиксез мәхәббәт, эти-әни белән горурлану хисләре белән сугарылган.
Махсус QR-код буенча үтеп, һәрбер җырның видеоязмасын карарга мөмкин.

**Бакиров, Растям Сайфуллович**
Б19 Пусть звучат песни славных лет: стихи, песни на татарском языке [сост. А.И.Хадеева]. – Казань: «Халкыбыз мирасы», 2024. – 40 стр.

Этот сборник включает стихи, песни, написанные в разные годы известным хирургом, общественным деятелем, Заслуженным врачом Российской Федерации и Республики Татарстан Растямом Бакировым. Его творчество пронизано чувствами безграничной любви к родному краю, родной земле, гордости и благодарности родителям.
Отсканировав QR-код с помощью смартфона, можно посмотреть видеозаписи песен.

© Бакиров Р.С., 2024
® «Халкыбыз мирасы», 2024

Туган җирем миңа шулкадәр күп нәрсә бирде ки, үземнең дә яхшылыкка яхшылык белән җавап кайтарасы килде. Адәм баласы моңсуланганда, җаны уйнаганда һәрвакыт туган йортына, ата-анасы хозурына килә, нигезенә кайта яисә су буйларына чишмәләр җырын тыңларга бара.

Әйе, безне үз бишегендә үстергән, аннан аякка бастырган һәм олы юлга чыгарган Туган җиребезне һәммәбезгә дә ныклап кайгыртырга күптән вакыт. Тамырлары шул җиргә береккәннәрнең һәркайсы аңа ярдәм итә ала. Туган авылдагы һәр мизгел күңелдә якты хатирә булып яңара.

Безнең җаннарыбыз авылда!

*Рөстәм Бакиров*

# КАЙТЫП БАРАМ ТУГАН ЯГЫМА

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Зөфәр Хәйретдинов музыкасы*



Сагынуга түзеп буламыни?
Кайтып барам туган ягыма.
Чал башларым күккә тияр кебек,
Менгән чакта Бизнә тавына.

*Кушымта:*
Тирә-якны көмеш чыңга күмеп
Үтәш чишмәләре челтери.
Чишмә суы, анам сөте кебек,
Изге моңнар булып җанга сеңеп,
Безгә бәхет, исәнлек тели.

Монда минем әби-бабаларым,
Дога кылам алар рухына.
Көмеш тәңкә салам, йоласы шул,
Үтәш чишмәләре суына.

*Кушымта.*

Сукмаклардан үтәм яланаяк,
Балачагым йөгерә каршыма.
Бизнәкәем, сагынып кайткан балаң
Якты йөзең белән каршыла.


*Кушымта.*

КАЙТЫП БАРАМ ТУГАН ЯГЫМА

# БӘРӘҢГЕГӘ МӘДХИЯ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* | *Тәлгать Вәлиев музыкасы*






Бәрәңгене бик яратып,
Икенче икмәк диләр.
Тәмле дә ул, туклыклы да –
Мактап бер җырлап җибәр!

*Кушымта:*
Язлар җиткәч бәрәңгене
Утыртабыз кадерләп.
Үзең үстергән бәрәңге
Бар нәрсәдән тәмлерәк.

Яшел була, ямьле була
Бәрәңге сабаклары.
Шул ярмалы бәрәңгенең
Тәмле була ашлары.

*Кушымта.*

Сине зурлап, рәхмәт әйтеп,
Халкым сиңа баш ия.
Бүген бездә зур тантана,
Җырлыйм сиңа мәдхия!
Бәрәңгегә мәдхия!

Бәрәнгегә мәдхия

# БИЗНӘБЕЗ БАТЫРЛАРЫ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Рөстәм Сәрвәров музыкасы*



Шаулап тора Бизнә ягы,
Матур бүген бигрәк тә.
Егетләрнең асыллары
Җыелганнар көрәшкә.

*Кушымта:*
Әйдә, әйдә, әйдә, күтәреп сал –
Мәйданнар гөрләп торсын әле!
Бизнәнең чын батырлары шулай
Гел артып торсын әле.

Тирәндә безнең тамырлар,
Онытмабыз аларны.
Ата-бабалардан яшьләргә күчкән
Бил алышу дәрманы.

*Кушымта.*

Дәвамлы варислар булгач,
Куәтле безнең халык.
Татар Бизнәсе батырларын чөя,
Яшәсеннәр макталып.

*Кушымта:*
Әйдә, әйдә, әйдә, күтәреп сал –
Мәйданнар гөрләп торсын әле!
Бизнәнең чын батырлары шулай
Гел артып торсын әле.
Бизнәнең чын батырлары!

Бизнэбез батырлары

## ӘТКӘЙГӘ ХАТ
поэма-монолог

Бөек Ватан сугышы каһарманы һәм хезмәт батыры булган кадерле Әтиебезгә – «Батырлык өчен», «Ленинград оборонасы өчен», «Берлинны алган өчен» медальләре, Кызыл Йолдыз һәм III дәрәҗә Дан орденнары кавалеры Сәйфулла Атаулла улы Бакировка.

*«Үткәннәргә хатлар бармый, диләр...*
*Бара алар – туса зур теләк! –*
*Газиз Әткәң торса күз алдыңда,*
*Булып сиңа һәрчак нык терәк!..»*

Шаһинур Мостафин,
эзтабар әдип һәм шагыйрь.

Шагыйрь хаклы: еллар үткән саен,
Якыная безнең аралар!
Синең күзләр, нәкъ элекке кебек,
Сынап һәм яратып багалар...

Сине сагынуларым чиктән ашкач,
Җырга күчердем мин хисләрем!..
...Рәсемеңә карап еш уйланам –
Тынгы таба алмыйм кичләрен...

«Исән чакта, Сине тиешенчә
Кадерләдек микән?» – дип уйлыйм.
Хыялымда һәм өнемдә кайтып,
Туган-үскән җирне еш урыйм!

Искә төшә һаман малайчаклар...
Таулар, су буйлары, таллыклар
Күз алдымда тора гомер буе,
Алар – безнең тиңсез байлыклар!

Искә төшә Сабан туйлары да:
Бил алыштык, мәйдан тоттык без!
Курыкмыйча чыккач көрәшергә,
Тормышта да күпне оттык без!..

Көрәшергә синнән өйрәндек без! –
Гадел, көчле булдың һәр чакта.
...Инде менә хәзер җылынабыз
Син кабызган сүнмәс учакта!

Ул учакны җиде телле, диләр...
Без дә җиде егет – бертуган!..
Һәркайсыбыз, бөркетләргә охшап,
Тормыш киңлегенә омтылган!

Югалмадык гомер юлларында,
Сөйгән ярны таптык һәм эшне...
«Сәйфулланыкылар булдыра!» – дип,
Горурланып әйтте күп кеше...

Әниебез дә шуңа яраткандыр –
Синең өчен торды өзелеп!
Үзең дә бит аны хөрмәт иттең –
Була белдең һәрчак ир-егет!

«Егетлек ул көрәш мәйданында,
Яуда беленә!» – дип сөйлиләр...
Әле һаман орден-медальләреңң,
Чыңлап, «Җиңү җыры»н көйлиләр!

«Җиңү таңын тизрәк аттырыйм!» – дип,
Яшьләй ут эченә кергәнсең...
Ләбиб кебек батыр дускаеңның
Вакытсыз үлемен күргәнсең...

Сапер булган Синең ул якташың –
Дошман миналарын юк иткән!
Ә син исә күперләр салгансың –
Җиңүгә юл шуннан да үткән!

Ләбиб дустың һәлак булган көнне
Гел исеңдә тоттың, Әтием...
Уйлангансың: «Ошбу авыр хәлне
Якыннарына ничек әйтием?!»

Алып кайткансың Син туган якка
Шәһит киткәнлеге хәбәрен...
Үз улыңдай сөеп малаен да,
Җиңеләйткәнсең гаилә хәлләрен!

...Инде ул малай да – бабай хәзер:
74 ел үткән сизелми!..
«Ә йөрәктә сагыну ялкыннары
Еллар үткәч тә һич сүрелми», –

Дия безгә Ләбиб батыр улы –
Рафаил абый үзе дә...
Мөлдерәпләр карый бер фотога –
Энҗе бөртекләре күзендә.

Ул фотода Ләбиб батыр белән
Әти, синең дә бар сурәтең...
«Чын дуслыкның нинди булганлыгын
Аңлатты ул безгә, өйрәтте!» –

Диеп, янә Рафаил абый
Кат-кат карый ошбу фотога –
Күңелендәге эч серләрен сөйли
Яудан кайтмый калган атага!

Ә безнеке кайткан – Берлинны алып! –
Дусты өчен дә ул сугышкан:
«Җиңелмәссең, кан эчүче фашист! –
Батырлык хас безгә тумыштан!»

Шулай дигән Атаулла улы –
Сәйфулла ул! – Безнең Әткәбез!..
Еллар аша хөрмәтебез арта,
Зур горурлык белән әйтәбез:

«Чын батыры булган Илемнең!» – дип...
Шигырьләргә керттек исемен!
(Энекешләрем дә шигырь яза –
Исен китәреп һәр кешенең!)

Шул уңайдан, Тәлгать энемнең дә
Шигыреннән алып бер өзек,
Биредә аны язып үтим әле –
Әткәм тыңласын, – дип, – сөенеп!

«Син үзең дә, Әтәй, Җиңү байрагын
Элгән каһарманга тиңдәштер –
Берлин өчен барган сугышларда
Гази Заһитовка иңдәштер!

Син дә күтәрештең ул Байракны,
Кайнар каның тамды аңарга:
Йөрәк яның ядрә тишеп үтте...
Исән калдың!!! Кирәк данларга!..

Егылып калган булсаң чит-ят җирдә –
Без тумаган булыр идек лә...
Син булганга һәм Әнәй булганга –
Бу дөньяга без бит килдек лә!»

Әкияттәге җиде егет кебек,
Сөендереп Әткәй-Әнкәйне
Яшәдек һәм яшибез җирдә!..
Сүздән коеп Сезгә һәйкәлне,

Мең рәхмәтләр әйтәсебез килә –
Сез бит моңа күптән бик лаек:
Безнең замандашлар арасында
Исемегез йөрде макталып!

Гомер юлын намус белән үтеп,
Бакыйлыкка инде күчтегез...
«Сезне уйлап, дога кылып үтә
Фанилыкта иртә-кичебез!» –

Шулай дия Марифә апабыз да –
Сеңелең Синең күпне кичергән...
Хәтер дисбесе гел кулларында,
Һич чыгармый Сине исеннән!

Дәвамчыларың да шактый инде –
Егерме оныгың бар!.. Ходайга
Рәхмәтләр әйтеп яшәсәк гел,
Эшләр барыр, димен, уңайга!..

Әткәй! Синең дустың Ләбибнең дә
Улы сынатмаган тормышта:
Әтисенең рухын зурлаган ул
Һәр адымда, һәрбер сулышта!

Рафаил абый – Зәкия апа белән –
Донбасс төбәгендә эшләгән...
Батыр шахтер булгач, данлы исемен
Яңгыраткан – телдән төшмәгән!

Безнең халыкка бит батырлык хас! –
Яу кырында булсын, хезмәттә...
Шул батырлык күчә каннар аша,
Чын Кеше булырга өйрәтә!

Без дә шулай үстек... Үрнәк булдың
Бар сыйфатың белән тормышта!
Үзеңне Син батырларча тоттың
Алган чакта соңгы сулыш та...

Йөрәк тибешең тоям һаман, Әткәй,
Соңгы тапкыр кулым кысканың...
Шул тибешне һәрчак сизеп торам,
Үтим әманәтең – кушканың!

Ә теләгең изге иде, Әткәй,
Ургып чыкты сүзләр авызыңнан:
«Йөрәгемнең көчен, сүнмәс дәртен
Улларыма күчереп калдырам!

Кирәк булса, аны факел итеп,
Барыр юлыгызда яндырам!!
Оныкларым да аннан дәрман алсын –
Шуны тели минем җан гынам!!!»

Әткәй, күчтең инде йөрәкләргә –
Минем йөрәктә дә шул йөрәк!
Минем йөрәк – Синең йөрәк кебек,
Бергә типкәч – нинди зур терәк!

Шулай дия барлык улларың да,
Киленнәрең дә! – Барысы сагына!
Кызлар, кияүләр һәм оныклар белән
Баш иябез Синең алдыңда!
Баш иябез Әнкәй алдында!

(Икегез дә безгә бик кадерле,
Икегез дә – йөрәк түрендә!)
Тормыш юлын матур үттегез –
Җәннәттә дә шуңа Сез бергә!!)

* * *

Ләбиб дускаеңның улы белән
Элемтәбез нык, һич тә өзелми! –
Мунчәли һәм Татар Бизнәсендә
Ихлас дуслык хисе сүрелми...

Рафаил ага һәм Зәкия апа
Дүрт балага гомер биргәннәр!
Румил исемлесе һәлак булган
Әфган җирендә... «Тагын тилгәннәр

Очып йөри Донбасс күгендә!» – дип,
Өзгәләнә шахтер үзәге...
Әйтегезче, җирдәшләрем минем,
Сугышның соң бармы кирәге?

Сугышлардан гарык булдык инде...
Күңел теле бары Тынычлык! –
Әтием әйтә кебек еллар аша:
«Шуның өчен дә бит тырыштык!»

...Һич кенә дә тыныч карый алмыйм
Дәһшәтле шул сугыш чорларын.
Күңелемнән ургыла да чыга
Хәтер төпкеленнән җырларым!

Ул җырларда, Әткәй, Синең аваз,
Синең батырлыгың, куәтең!
«Җырлап яшә, улым, тормышта!» – дип,
Яшь чактан ук үзең өйрәттең!

Син башлаган җырны дәвам итәм:
Синең җырың бит ул, Әтием!
Алмаш булып килгән варисларга:
«Синең васыятең!» – дип әйтермен...

# БАТЫРЛАРГА

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Тәлгать Вәлиев музыкасы*



Яу кырында калган дусларыңны
Чыгармадың, әти, хәтердән.
Батырларга мәңге рәхмәтле без –
Алар илгә җиңү китергән.
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Яралары әрнеп сызласа да,
Утка кыю кергән бит алар.

Тимер ярчык кереп яшеренгән
Баһадирдай көчле гәүдәңә.
Шартлаткыч та сине җиңә алмаган,
Ходай үзе саклап йөргәнгә.
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Яралары әрнеп сызласа да,
Утка кыю кергән бит алар.

Бәхилләшкән чакта: Улым, диеп
Соңгы тапкыр кыстың кулымны.
Көч-кодрәтең бирдең гомерлеккә,
Җиңеләйттең узар юлымны.
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Яралары әрнеп сызласа да,
Сер бирмәгән, түзгән бит алар.

Сиңа лаек уңган улларың да
Туган җиргә тугры һәм тырыш.
Имәндәй нык нәсел тамырыбыз,
Гөрләп тора безнең дә тормыш.
Бөек җиңү көнен якынайткан
Курку белмәс батыр солдатлар.
Батыр солдат булып илебезгә
Җиңү яулап кайткан бит алар.
Җиңү яулап кайткан батырлар!

Батырларга

Батырларга - клип

# АК ХАЛАТЛЫ ФӘРЕШТӘЛӘР

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Айдар Фәйзрахманов музыкасы*



Гомерләрне мизгел хәл иткәндә
Сират күперләре кичәбез.
Үлем белән яшәү арасында
Сез, табиблар, ярдәм итәсез.

*Кушымта:*
Ак канатлы фәрештәләр оча,
Ак халатлы фәрештәләр була.
Безне саклар өчен табибларга
Кодрәтеңне бирче, йә Хода.

Үзе биргән антка тугры калып,
Авыр чакта килеп яныңа
Гомер җебен кабат ялгап куя,
Җибәрмичә күкләр катына.

*Кушымта.*

Әҗәл фәрештәгә баш имичә,
Яшәү өчен көрәш барганда
Зур батырлык кыла һәрбер табиб,
Аллаһы ярдәм итсен аларга.

*Кушымта.*

"Ак халатлы фэрештэлэр"

# ТАБИБЛАРГА

*Рөстәм Бакиров сүзләре* | *Оскар Усманов музыкасы*



Сәгать түгел, минут хәл иткәндә
Сират күпереннән үтәбез.
Яшәү белән үлем тартышканда
Табиблардан ярдәм көтәбез.

*Кушымта:*
Ак канатлы фәрештәләр күктә,
Җирдәгеләр ап-ак халаттан.
Гомер өстәр дәвачылар итеп
Табибларны Ходай яраткан.

Гиппократ антына тугъры калып,
Вакытында килеп ярдәмгә,
Якты өмет җебен ялгый табиб
Әҗәл кулындагы адәмгә.

*Кушымта.*


Аяусыз үлемгә баш имичә
Яшәү өчен көрәш барганда,
Чын батырлык эшли һәрбер табиб
Әҗәл угын тартып алганда.

*Кушымта.*

Сэгыйть Гыйбашев "Табибларга"

# ТАБИБЛАРНЫ ХОДАЙ ЯРАТКАН

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Сабит Миңнеханов музыкасы*



Сәгать түгел, минут хәл иткәндә
Сират күпереннән үтәбез.
Яшәү белән үлем тартышканда
Табиблардан ярдәм көтәбез.

*Кушымта:*
Ак канатлы фәрештәләр күктә,
Җирдәгеләр ап-ак халаттан.
Гомер өстәр дәвачылар итеп
Табибларны Ходай яраткан.

Үзе биргән антка тугъры калып,
Вакытында килеп ярдәмгә,
Якты өмет җебен ялгый табиб
Әҗәл кулындагы адәмгә.

*Кушымта.*

Аяусыз үлемгә баш имичә
Яшәү өчен көрәш барганда,
Чын батырлык эшли һәрбер табиб
Әҗәл угын тартып алганда.

*Кушымта.*

# ЯТИМ БАЛА

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Гөлнирә Абдрахманова музыкасы*



Көтәм сезне олы юлга чыгып.
Һәркөн саен күзлим зарыгып
Мине сердәш итеп челтрәп аккан
Бабай чишмәсеннән, чәй куеп.

*Кушымта:*
Әткәй-әнкәй, көтәм бергә кочып,
Чәчләремнән сыйпап үпкәнне.
Әллә инде кайтыр юлларыгыз
Ялгыш юлга сезне керткәнме?

Түбән очның урамында йөргән,
Әллә шунда кайтыр юлларыгыз?
Бәрәңгеләр пешереп сезне көтә
Төп нигездә сезнең улыгыз.

*Кушымта.*

Бәлки сез дә эзлисездер әле.
Еракмы соң кайтыр юлыгыз?
Үзем киләм, бәгырьләрем минем,
Сез сузыгыз гына кулыгыз.

*Кушымта.*

Ятим бала

* * *

Безнең тамырлар – Бизнәдә!–
Бик тә, бик тә тирәндә...
Үтәш биләр, Мәрҗаниләр
Яши кебек тирәмдә.

Алар рухы яши бездә –
Шуңа көләч йөзебез,
Киңдер безнең күңелебез,
Хактыр әйтер сүзебез!

Әткәй-Әнкәйләрдән күчкән
Түземлек һәм Сабырлык,
Тырышлык һәм Максатчанлык... –
Баксаң, хәйран калырлык!

Горур да без, үзсүзле дә,
Вәгъдә биргәч, үтибез!
Сөйгәннәрне кадерлибез,
Яннарыннан китмибез!

Гаилә җылысын саклыйбыз –
Сүндермибез Учакны!
Каршылыйбыз җан дусларны –
Ихлас җәеп кочакны!

Җыр тыңларга яратабыз,
Җырларга да! – хисле без...
Дәвалыйбыз кешеләрне,
Тылсымчыдай көчле без!


...Безнең тамырлар – Бизнәдә!
Изге җирдә – тирәндә...
Үтәш биләр, Мәрҗаниләр
Көч-дәрт бирә тирәмдә!

## ВАСЫЯТЬНАМӘ

Үсә төшкәч, бу китапны
Укып чыгарсың әле.
Анда – мең сорауга җавап,
Анда – яшәүнең мәне.
Анда – ата-бабаларның
Һәм минем тормыш гаме.
Күрерсең үз гомеремдә
Кылган барча гамәлне.
Һәр гамәлнең асылына
Төшеп фикер йөрт, яме!
Нәселең белән горурланырсың,
Кайчак хәйран калырсың.
Хатам булса, кичерерсең –
Үзеңә сабак алырсың!..
Ата-бабаң үткән юлны
Хәтереңә салырсың.
Синең һәм туганнар өчен
Яздым ошбу китапны.
Зурладым нәсел-ыруны,
Авылны, Туган якны!
Син аны дәвам итәрсең,
Арткач тормыш тәҗрибәң.
Керми калган хәлләр булса,
Аны да кушып җибәр.
«Өзелмәсен шәҗәрәм», – дип,
«Югалмасын дәрәҗәм», – дип,
Ал да кулга каләмең,
Теркә изге гамәлең.
Каләмеңнән төшкән һәр сүз
Килер буынга калсын –
Укып гыйбрәтләр алсын да
Юлыннан горур барсын!..

# ИҢ ШӘП БАБАЙ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* — *Рөстәм Сәрвәров музыкасы*



Сөенеп туймас балачак,
Иң бәхетле балачак.
Бабай белән үткән кичләр
Мәңге истә калачак.

*Кушымта*:
Яратабыз сине, бабай.
Син бит безнең бер генә.
Нурлы йөзле, шат күңелле,
Иң шәп бабай – син генә!

Синең эзләр сакланадыр
Бормалы сукмакларда.
Һәй, бабакай, диябез без
Бик сагынган чакларда.

*Кушымта.*


Без бәхетле синең белән,
Син бәхетле без барда.
Үтәшләр рухы ага бит
Безнең дә тамырларда.

*Кушымта.*

"Ин шэп бабай"

# ӘБИЕМ, ӘБЕКӘЕМ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Рөстәм Сәрвәров музыкасы*



Балам дия-дия безне
Кадерләп үстерәсең.
Әй, матур син, әбекәем,
Күзләр тия күрмәсен!

*Кушымта:*
Әй, әбием, әбекәем,
Кояш кебек күңелең.
Сәламәтлек бирсен Ходай,
Озын булсын гомерең.

Өебезнең нуры бит син,
Рәхмәт яусын үзеңә.
Бәхетлебез, әбекәем,
Син булган өчен генә.

*Кушымта.*


"Эбием эбекэем"

"Эбием эбекэем" А.Вэлиуллина

# КИТМӘМ, БИЗНӘМ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Шамил Тимербулатов музыкасы*






Су буенда таныш таллар һаман
Саклый безнең яшьлек серләрен.
Ничәнче кат инде кичерәм мин
Аерылышуның ачы хисләрен.

*Кушымта:*
Кара туфрагыңда яралдык та,
Ак бәхетләр эзләп киттек без.
Таралсак та төрле тарафларга,
Синдә яши безнең күңелебез.
Менә тагын озын юллар дәшә,
Яулык болгый Бизнә кызлары.
Сагышлана йөрәк шул чагында,
Һәм нечкәрә күңел кыллары.

Менә тагын озын юллар дәшә,
Яшел мәчет бирә фатыйха.
Китеп бара Үтәш онықлары
Сиңа кабат сагынып кайтырга.

*Кушымта.*


Җәйрәп ята икмәк тәме килгән
Гәрәбәдәй иген кырлары.
Тагын кайт, дип озатып калырлар
Бизнә тургаеның җырлары.

*Кушымта.*

"Китмэм Бизнэм"

# БАБАМНАР ВАСЫЯТЕ

*Рөстәм Бакиров сүзләре* *Рөстәм Сәрвәров музыкасы*



Нәсел тамырлары бик тирәндә,
Эзләп табыйк – кирәк һәркемгә дә.
Зур шәхесләр чыккан Бизнәбездән,
Хисләр ташый һәркем йөрәгеннән.
Һич тынмасын данлы чор җыры,
Өзелмәсен буын чылбыры!

Шул тылсымлы җырны отып алып,
Күңел түрләренә моңнар салып,
Килен-кияүләр дә була торсын,
Оныклар да күпләп туа торсын.
Юансыннар әби-бабайлар,
Яшәсеннәр безнең балалар!

Сөенерлек булсын һәр эшебез –
Татар Бизнәсеннән чын кеше без!
Васыятьнамә язган бабайларга
Рәхмәт әйтеп яшик һәр заманда.
Һич онытмыйк тарихи үткәнне,
Сокландырып яшик күпләрне!

"Бабамнар васыяте" М.Юлдашев

Бабамнар васыяте

## Факты биографии и творческого пути Растяма Бакирова

Растям Сайфуллович Бакиров – из рода татарских мурз. Родился 25 марта 1954 года в деревне Татарская Бездна Дрожжановского района ТАССР в дружной многодетной семье сельских тружеников. Отец Сайфулла, вернувшись с Великой Отечественной войны, преподаёт в школе физкультуру и труд. Позднее работает шахтёром, директором клуба, бригадиром. Его мама Рауза занималась ведением домашнего хозяйства и воспитанием семерых сыновей.

1962–1972 – обучался в Стародрожжановской средней школе.

1968–1984 – член ВЛКСМ.

1972–1978 – обучался в Казанском государственном медицинском интитуте на факультете «Лечебное дело» по специальности врач-хирург.

1976 – создал семью с Фаридой Мирхазияновной, урождённой Нагимовой из деревни Новые Шалты Бавлинского района Республики Татарстан.

1976–1978 – фельдшер здравпункта Казанского трамвайно-троллейбусного Управления.

1978–1979 – врач-интерн по хирургии Центральной районной больницы города Нижнекамск.

1979–1982 – врач-хирург Центральной районной больницы города Нижнекамск.

1982–1984 – обучался в клинической ординатуре на кафедре госпитальной хирургии № 1 Казанского государственного медицинского интитута.

1984–1994 – заведующий хирургическим отделением медико-санитарной части ПО «Нижнекамскнефтехим».

1988–1991 – член КПСС.

1990–1995 – Народный депутат Верховного Совета ТАССР XII созыва.

1992 – присвоено почётное звание «Заслуженный врач Республики Татарстан».

1994–2002 – главный врач Приволжского района города Казань.

1994–2017 – главный врач МУЗ «Центральной городской клинической больницы № 18» города Казань.

1999 – присвоено звание «Почётный член Академии Гуманитарных Наук (Академик)» города Санкт-Петербург.

1999–2005 – депутат Казанского городского Совета народных депутатов Республики Татарстан.

2000 – присуждена учёная степень Кандидата медицинских наук.

2004 – лауреат конкурса «Человек – золотое сердце».

2004 – присвоено почётное звание «Заслуженный врач Российской Федерации».

2005 – награждён медалью «В память 1000-летия Казани».

2006 – член-корреспондент Международной Гуманитарной Академии «Европа-Азия».

2009 – награждён памятной медалью Нижнекамской городской многопрофильной больницы № 3 «За заслуги перед больницей».

2009 – награждён памятной медалью «В память 50-летия здравоохранения Нижнекамска».

2009–2014 – депутат Государственного Совета Республики Татарстан IV созыва.

2010 – награждён медалью «За активную гражданскую позицию и патриотизм».

Член Комиссии Государственного Совета Республики Татарстан по контролю за реализацией национального проекта в сфере здравоохранения, членом Комиссии Государственного Совета Республики Татарстан по реализации молодежной политики, формированию здорового образа жизни и содействию подготовке XXVII Всемирной летней универсиады 2013 года в г. Казани, членом партии «Единая Россия», членом депутатской группы «ТНВ» в Государственном Совете Республики Татарстан.

2011 – подготовил и издал книгу об истории родного края «Безнең тамырлар – Бизнәдә!.. »

2012 – комитетом по проведению «Дня семьи, любви и верности в Российской Федерации» Фарида Мирхазияновна и Растям Сайфуллович награждёны медалью «За любовь и верность».

2014 – награждён знаком отличия «За безупречную службу Казани».

2015–2020 – депутат Казанской городской Думы.

2017 – награждён медалью ордена «За заслуги перед Республикой Татарстан».

2017–2021 – заместитель главного врача ГАУЗ «Центральная городская клиническая больница № 18» города Казань.

2024 – присвоено звание «Почётный гражданин Дрожжановского муниципального района Республики Татарстан».

Занимался гиревым спортом и национальной борьбой «Көрәш», имеет награды.

Вместе с женой Фаридой они вырастили и воспитали троих дочерей, которые также работают в сфере медицины. В свободное время Растям Сайфуллович с удовольствием проводит время со своими внуками, их у него девять.

По инициативе и содействию Растяма Сайфулловича Бакирова в его родной деревне Татарская Бездна Дрожжановского района проходят многочисленные мероприятия: 1000-летие деревни, возведение памятников, реставрация родников, облагораживание фасада мечети, посадка деревьев, ремонт Дома культуры, проведение Дней села с участием ведущих общественных, театральных деятелей и артистов татарской эстрады, спортивных турниров, праздничных мероприятий, посвященных знаковым событиям, таким как 135-летие Татарско-Безднинской школы, 90-летие со дня рождения Габдуллы Рахимкулова, 70-летие Победы в Великой Отечественной войне и др.

Сегодня автор работает над книгой о нравственном воспитании, миссии учителя, укреплении семейных традиций. Его жизненный путь является примером для подражания и образцом служения своему народу. Он очень любит свой народ, хочет видеть его счастливым, всегда готов откликнуться на просьбу о помощи и делает для блага своего народа всё, что от него зависит.

# ЭЧТӘЛЕК

1. Туган җирем ........ 5
2. Кайтып барам туган ягыма. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Зөфәр Хәйретдинов музыкасы* ........ 6
3. Бәрәңгегә мәдхия. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Тәлгать Вәлиев музыкасы* ........ 8
4. Бизнәбез батырлары. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Рөстәм Сәрвәров музыкасы* ........ 10
5. Әткәйгә хат ........ 12
6. Батырларга. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Тәлгать Вәлиев музыкасы* ........ 18
7. Ак халатлы фәрештәләр. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Айдар Фәйзрахманов музыкасы* ........ 20
8. Табибларга. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Оскар Усманов музыкасы* ........ 22
9. Табибларны Ходай яраткан. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Сабит Миңнеханов музыкасы* ........ 24
10. Ятим бала. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Гөлнирә Абдрахманова музыкасы* ........ 26
11. «Безнең тамырлар Бизнәдә...» ........ 28
12. Васыятьнамә ........ 29
13. Иң шәп бабай. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Рөстәм Сәрвәров музыкасы* ........ 30
14. Әбием, әбекәем. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Рөстәм Сәрвәров музыкасы* ........ 32
15. Китмәм, Бизнәм. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Шамил Тимербулатов музыкасы* ........ 34
16. Бабамнар васыяте. *Рөстәм Бакиров сүзләре, Рөстәм Сәрвәров музыкасы* ........ 36
17. Факты биографии и творческого пути Растяма Бакирова ........ 38

Ошбу җыентык Фәнис Рәшит улы Айсин
ярдәме белән нәшер ителде.

Ноталы басма

**Бакиров** Рөстәм
(**Бакиров** Рөстәм Сәйфулла улы)
**ҺИЧ ТЫНМАСЫН ДАНЛЫ ЧОР ҖЫРЫ**
Шигырьләр, җырлар

Нотное издание

**Бакиров** Растям
(**Бакиров** Растям Сайфуллович)
**ПУСТЬ ЗВУЧАТ ПЕСНИ СЛАВНЫХ ЛЕТ**
Стихи, песни
на татарском языке

Составитель, музыкальный редактор *Альфия Хадеева*
Компьютерный набор нотного текста *Гульнара Беляева*
Техническое редактирование, компьютерная вёрстка *Азат Низамиев*
Ответственный редактор *Рустам Сарваров*

6+ Знак информационной продукции согласно ФЗ от 29.12.2010 № 436-ФЗ

Подписано в печать 05.04.2024. Формат 60x84 $^{1}/_{8}$.
Усл. печ. л 5,0. Тираж 100.

ООО «Халкыбыз мирасы»
420073, Республика Татарстан, г. Казань, ул. Спортивная, дом 33, офис 1
http:// miras.tatar

